| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФЕДОРОВСКИЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025е. Федоровский ав. № 11

Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге территориясендә терлекләрне хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннарны билгеләү һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Терлекләр белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Терлекләр белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы федераль закоңнар, «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Федоровский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче хуҗалардан башка хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннарның беркетелгән исемлеген расларга
2. Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесен Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге территориясендә хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле вәкил итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге https://fedor-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча

Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Федоровский авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Ф.Ф.Зәйнуллин

Кайбыч муниципаль районы
Федоровский авыл җирлеге
Башкарма комитетының
21.11.2025е. 11 номерлы карарына
кушымта

Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннар
ИСЕМЛЕГЕ

- гомуми файдаланудагы территорияләр (шул исәптән мәйданнар, урамнар, машина юллары, парклар, скверлар һәм башка территорияләр, алар белән чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдалана);
- күпфатирлы йортларга якын территорияләр;
- балалар өчен уен һәм балалар спорт мәйданчыклары;
- актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;
- массакүләм чаралар уздыру өчен мәйданчыклар;
- балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре;
- мәдәният объектларына якын территорияләр;
- җәмәгать туклануы оешмаларына, кибетләргә якын территорияләр.